**Татар теленнән БДТның һәм БДИның С өлешенә әзерләнү өчен**

**әдәби әсәрләрдән, халык авыз иҗатыннан аргументлар**

Хәбибуллина Айгөл Фәнзәт кызы
Түбән Мактама 1нче гомуми урта
белем бирү мәктәбенең татар теле
һәм әдәбияты укытучысы

Татар теленнән БДТ һәм БДИга әзерләнгәндә укучылар өчен аеруча иҗади эш – С өлеше катлаулы. Укучылар бирелгән тема буенча сочинение язганда әдәби әсәрләрдән, халык авыз иҗатыннан аргументлар китерергә авырсыналар.

Түбәндәге таблицада актуаль темалар буенча аргументлар җыелмасы бирелә.

| **Тема** | **Әдәби әсәрдән мисаллар** | **Халык авыз иҗатыннан мисаллар** (мәкаль-әйтемнәр) |
|---|---|---|
| **Туган җир, Ватан** | Гомәр Бәшировның “Туган ягым – яшел бишек” повесте; Габдулла Тукайның “Туган авыл” шигыре; Гадел Кутуйның “Сагыну” нәсере һ.б. | Туган туфракка баскан эз суынмый.<br>Туган илнең кадерен читтә йөрсәң белерсең.<br>Туган җирдәй җир булмас, туган илдәй ил булмас. |
| **Хезмәт, тырышлык** | Габдулла Тукайның “Эшкә өндәү”, “Эш беткәч уйнарга ярый”; Абдулла Алишның “Ялкаулык – хурлык, тырышлык - зурлык” әкияте; Шәриф Камалның “Акчарлаклар” повесте (Гариф, Газизә образлары) | Кем эшләми – шул ашамый.<br>Тырышлык – зурлык, ялкаулык – хурлык.<br>Егет кешегә 70 төрле һөнәр дә аз.<br>Агач - җимеше белән, кеше - эше белән.<br>Агачны яфрак бизәсә, кешене хезмәт бизи. |
| **Экология, табигать** | Илдар Юзеевның “Гашыйклар тавы” әсәре, Гомәр Бәшировның  “Туган ягым – яшел бишек” | Җир чокырсыз булмас, урман киексез булмас.<br>Җире байның иле бай. |
| **Мәхәббәт** | Илдар Юзеевның “Гашыйклар тавы” (Сәет - Мөнирә)  әсәре, “Таныш моңнар” (Зөфәр - Резидә) поэмасы; Фәнис Яруллинның “Җилкәннәр җилдә сынала” (Фәнияр - Илсөя) повесте; Шәриф Камалның “Акчарлаклар” повесте (Гариф - Газизә), Мирхәйдәр Фәйзинең | Дөнья күрке сөйгән яр белән.<br>Дөньяда өч нәрсә юк: диңгезгә-капкач, күккә - баскыч, мәхәббәткә - дару.<br>Матурлык туйда кирәк, мәхәббәт көн дә кирәк.<br>Мәхәббәт акчасыз да бакча ясый. |

| | | |
|---|---|---|
| | “Галиябану” драмасы (Хәлил-Галиябану) | |
| **Дуслык** | Һади Такташның “Мокамай” шигыре (автор һәм Мокамай дуслыгы); Фәнис Яруллинның “Җилкәннәр җилдә сынала” (Фәнияр һәм Илдус Гаделшин дуслыгы) повесте һ.б. | Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын.<br>Яхшы дус алтыннан кыйммәтрәк.<br>Дустың начарлык эшләсә комга яз, яхшылык эшләсә ташка яз.<br>Дустың үзеңнән яхшырак булсын. |
| **Татар халкы: тел, милләт язмышы** | Хәсән Туфанның “Туган тел турында җырлар”, “Кемнәр Сез?” шигырьләре, Габдулла Тукайның “Туган тел”, “Милли моңнар” шигырьләре; Гаяз Исхакыйның “Җан Баевич” (Шакирҗан –Җан Баевич) комедиясе һ.б. | Тел - ананың теләге,<br>Тел - ананың баласына иң кадерле бүләге.<br>Телләр белгән - илләр белгән.<br>Тел ташны эретә. |
| **Игелек, яхшылык** | Аяз Гыйләҗевның “Җомга көн, кич белән” повесте (Бибинур образы); Габдрахман Әпсәләмовның “Ак чәчәкләр” романы (Гөлшәһидә, Әбүзәр Таһиров һәм Мансурның игелекле эш-гамәлләре) | Изгелек – кояш нурына тиң.<br>Яхшылык күрәсең килсә, яхшылык ит.<br>Көн саен игелек кыл.<br>Яхшылык җирдә ятмас.<br>Яхшылыкка - яхшылык. |
| **Үкенү** | Шәриф Камалның “Буранда” хикәясе (Мостафа образы), Шәриф Камалның “Уяну” хикәясе (Муса образы) | Яшьлегеңдә өйрәнмәсәң, картлыгыңда үкенерсең.<br>Кылган гамәлләрең өчен үкенерлек булмасын! |
| **Ата-ана һәм балалар** | Шәриф Камалның “Буранда” хикәясе; Фәнис Яруллинның “Ана” балладасы | Ана күңеле балада, бала күңеле далада.<br>Әткәй шикәр - әнкәй бал.<br>Ата-ана йөрәгенең тирәнлеген балалар белми. |
| **Батырлык** | Самат Шакирның “Үлемнән көчлерәк” очеркы (Хәйретдин Мөҗәй батырлыгы); Г абдрахман Әпсәләмовның “Газинур” (Советлар Союзы герой Газинур Гафиятуллин батырлыгы), “Алтын йолдыз” романнары | Батыр бер үләр, куркак мең үләр.<br>Батыр ярасыз булмас.<br>Батыр үзе өчен туар, кеше өчен үләр.<br>Батырлыкта - матурлык.<br>Батыр үзе үлсә дә, исеме үлмәс.<br>Батыр егет - ил күрке. |